| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.09.2018 г.Казань № 842

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 1 октяберендә 4904 номеры белән теркәлде

Халыкны эшкә урнаштыру өлкәсендә
дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым
административ регламентларына
үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне (алга таба – Үзгәрешләр) расларга.

2. Әлеге боерык белән расланган Үзгәрешләрнең 1 пунктының утыз җиденче-кырык беренче, кырык дүртенче-кырык алтынчы абзацлары, 2, 3 пунктларының унсигезенче-егерме икенче, егерме бишенче-егерме җиденче абзацлары 2018 елның 18 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 10.09.2018
№ 842 боерыгы белән расланды

Халыкны эшкә урнаштыру өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы хезмәт базарында эшсез гражданнарның социаль адаптациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 сентябрендәге 649 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, от 28.09.2016 №549, 12.07.2018 № 550 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы хезмәт базарында эшсез гражданнарның социаль адаптациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәге урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) ХМҮ бүлмәләрендә урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы [1] (http://www.mtsz.tatarstan.ru), ХМҮ рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://www.uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) КФҮ, читтән торып эшләү урынына мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

5) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2002, № 1, 3 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

---

[1] Алга таба – Министрлык

«Россия Федерациясендә халык мәшгульлеге турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1996, № 17, 1915 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);[2]

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүмат яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);[3]

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);[4]

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2013, № 14, 1652 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);[5]

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);[6]

«Дәүләт вазыйфаларын үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында» 2011 елның 16 маендагы 373 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 22, 3169 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү буенча чараларны финанслау тәртибе турында нигезләмә раслау турында» 2005 елның 29 июлендәге 485 номерлы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы («Российская газета», 2005, 30 сентябрь);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Халыкның (физик затларның һәм эш бирүчеләрнең) мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучыларның регистрларын алып бару тәртибе турында, аларга белешмәләр бирү тәртибен, срокларын һәм формасын да кертеп» 2010 елның 8 ноябрендәге 972н номерлы боерыгы («Российская газета», 2011, 2 февраль);

«Хезмәт базарында эшсез гражданнарның социаль адаптациясе буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 9

---

[2]Алга таба – Халык мәшгульлеге турында закон

[3] Алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон

[4] Алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон

[5] Алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон

[6] Алга таба – 601 номерлы Указ

гыйнварындагы 3н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы («Российская газета», 2013, 22 май);[7]

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халык мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 6 апрель);[8]

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 4 июнь);

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы Законнар җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы Законнар җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;[9]

1.9 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).»;

5 бүлектә:

5.1 пунктының өченче абзацын төшереп калдырырга;

5.2 пунктында:

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;»;

---

[7] Алга таба – 3н номерлы Федераль стандарт

[8] Алга таба – 125н номерлы боерык

[9] Алга таба – ТР МК 880 номерлы карары белән расланган Тәртип

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.»;

5.5 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;»;

5.6 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм курсәтү дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 сентябрендәге 674 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 12.07.2018 № 550 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм курсәтү дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәге урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) ХМҮ бүлмәләрендә урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы [9] (http://www.mtsz.tatarstan.ru), ХМҮ рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://www.uslugi.tatarstan.ru);

---

[9] Алга таба - Министрлык

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) КФҮ, читтән торып эшләү урынына мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

5) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.9 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).»;

5 бүлектә:

5.1 пунктының өченче абзацын төшереп калдырырга;

5.2 пунктында:

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;»;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.»;

5.5 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;»;

5.6 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән

уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.».

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 12.07.2018 № 550 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәге урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) ХМҮ бүлмәләрендә урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы [10] (http://www.mtsz.tatarstan.ru), ХМҮ рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://www.uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) КФҮ, читтән торып эшләү урынына мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

5) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.6, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.9 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү

---

[10] Алга таба - Министрлык

күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).»;

5 бүлектә:

5.1 пунктының өченче абзацын төшереп калдырырга;

5.2 пунктында:

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;»;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.»;

5.5 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;»;

5.6 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.».